КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 октябрь г.Казань № 993

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче; 2018 ел, 14 июнь, 472 нче; 2019 ел, 13 июнь, 487 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 748 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 926 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Күпфункциональ үзәкләр яки алар тарафыннан җәлеп ителүче чит оешмалар күрсәтә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр» дигән IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 28 – 38 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «28. | Акча тапшыру турында расписка төзү |
| 29. | Гариза язу |
| 30. | Дәгъваны, шикаятьне, хатларны, соратуларны һәм башка корреспонденцияне төзү |
| 31. | Шартнамәгә, килешүне өзү турындагы килешүләргә үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешү төзү |
| 32. | Составление устава юридического лица |
| 33. | Бердәнбер гамәлгә куючы карарын, юридик зат төзү турында беркетмәне, башка хокук билгеләү документларын төзү |
| 34. | Ламинирлаштыру |
| 35. | Сканлаштыру |
| 36. | Документлар бастыру |
| 37. | Текст җыю |
| 38. | Фото хезмәтләр»; |

V бүлекнең «Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 8 – 10 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «8. | Сканлаштыру |
| 9. | Юридик затның уставын төзү |
| 10. | Бердәнбер гамәлгә куючы карарын, юридик зат төзү турында беркетмәне, башка хокук билгеләү документларын төзү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин